# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Эшчәнлекнең аерым бер төрләре өчен йөкләтелгән керемгә бердәй салым турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында**

**1 статья.** «Эшчәнлекнең аерым бер төрләре өчен йөкләтелгән керемгә бердәй салым турында» 1999 елның 17 ноябрендәге 2439 номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына, түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«8 статья. Бердәй салым суммаларын түләү тәртибе

Бердәй салым суммалары федераль бюджетка, бюджеттан тыш дәүләт фондларына, шулай ук Татарстан Республикасы бюджетына «Эшчәнлекнең аерым бер төрләре өчен йөкләтелгән керемгә бердәй салым турында» Федераль закон нигезендә түләнә.

Татарстан Республикасы республика бюджеты белән җирле бюджетлар арасында бердәй салым суммасын бүлү чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджет системасы турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә торган нормативлар буенча башкарыла.».

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң кимендә бер ай үткәч һәм эшчәнлекнең аерым бер төрләре өчен йөкләтелгән керемгә бердәй салым буенча чираттагы салым чорының беренче числосыннан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 20 сентябре
№ 1057